Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
“Средняя общеобразовательная школа №1”
Чистопольского муниципального района РТ

| **Рассмотрено** | **Согласовано** | **Утверждено** |
|---|---|---|
| на заседании ШМО | зам. директора | и введено в действие |
| протокол № _________ | «     » 08. 2024 ел. | Приказ № ___________ |
| от«   »_08. 2024 ел. | __________/Зайцева Ю.Г./ | от «     » 08. 2024 ел. |
| _______/Приданникова Е.М../ | | _____________/Islamova |

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Подписано: МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
DN: cn=МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, c=RU, o=МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №1" ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, email=chis.fbp@tatar.ru
Дата: 2025.01.28 11:22:34 +03'00'

# Рабочая программа

## дополнительного образования
## “Азбука журналиста” (“Журналист әлифбасы”)
## (направление: социально-гуманитарное)

Составитель: Хусаинова Гульназ Ильясовна

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
Протокол №______
от _________2024 г.

2024-2025 учебный год

## ЭЧТӘЛЕК

1. Аңлатма язуы_______________________________________________________3
2. “Журналист әлифбасы” түгәрәге эшен планлаштыру_____________________5
3. “Журналист әлифбасы” программасы___________________________________8
4. Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән уңышлар_____9
5. Әдәбият исемлеге____________________________________________________10

# “Журналист әлифбасы” түгәрәгенең
***программасы***

Төзеде: Чистай муниципаль районы
1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хөсәенова Гөлназ Ильяс кызы

**Аңлатма язуы**

“Журналист әлифбасы” иҗат түгәрәге укучыларны халкыбызның рухи-әхлакый кануннары белән таныштырырга, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтне үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү юнәлешендә эш алып бара. Түгәрәктә танып-белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла. Укучылар түгәрәктә газета-журналлар басу технологиясе, газета әсәрләре иҗат итү баскычлары (тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү, текст төзү, ритм, рифма һ.б.) журналистика жанрлары турында мәгълүмат алалар. Үзләре газета-журналлар өчен шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр иҗат итәләр, үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнәләр. “Көмеш кыңгырау” исемле мәктәп гәзитен чыгаралар. “Журналист әлифбасы” иҗат түгәрәгенең эшчәнлеген шул газета битләрендә яктыртып баралар.

Укытучы алдына куелган бурыч түгәрәк утырышларын мөмкин кадәр мавыктыргыч, җанлы, кызыклы итеп, төрле алымнар кулланып үткәрүдән гыйбәрәт.

Халык авыз иҗаты материалларыннан: әкият, табышмак, мәкаль-әйтемнәрдән файдалану бер үк вакытта ике бурычны үтәүгә хезмәт итә: беренчедән, алар укучыларга татар әдәбиятыннан, фольклорыннан белешмә бирә; икенчедән, иҗади эштә файдалану өчен материал булып тора.

Түгәрәк алдында торган иң мөһим бурычларның берсе шул: иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, укучылар “Сабыйга” журналын, “Сабантуй” газетасын даими укып барырга, татар спектакльләрен, балалар өчен татарча телевидение һәм радио тапшыруларын карарга һәм тыңларга, яңа чыккан әдәби әсәрләр белән танышып барырга тиешләр.

Уку елы башында балалар өчен булган вакытлы матбугатка күзәтү оештырыла. Укучыларның игътибарын газета–журналлардагы рубрика төрләренә, шигырьләрнең, мәкаләләрнең тематикасына, күтәрелгән проблемаларның актуальлегенә юнәлтү сорала.

Укучылар белән эшләү барышында аларның шәхси үзенчәлекләрен истә тоту бик әһәмиятле. Мәсәлән, һәр укучыга да шигырь язу сәләте бирелмәскә мөмкин.Кемдер үзен әкият иҗат итүдә, мәкалә язуда сынап карый ала. Кемдер вакытлы матбугатта басылган материалларны туплап, эшкәртеп, мәктәп газетасы өчен әзерләргә мөмкин. Шунлыктан, түгәрәк җитәкчесе алдында укучыларның иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү буенча җитди бурыч тора.

Укучылар эпитет, гипербола, литота, метафора, метанимия, сынландыру кебек сурәтләү чаралары турында хәбәрдәр булырга, аларны таный белергә, үз иҗатларында куллана белергә тиешләр.Бу сурәтләү чаралары белән таныштырганда районлаш язучы һәм шагыйрьләрнең әсәрләреннән файдалану аеруча отышлы.

Милли-төбәк компонентларыннан урынлы файдалану балаларда якташлары белән горурлану хисләре уята, патриотик тәрбия бирә.

Түгәрәкнең эше утырышлар дип аталса да, ул структур яктан традицион формадагы дәресләргә охшаган: оештыру, актуальләштерү, яңа материалны аңлату, ныгыту, йомгаклау. Дәресләрдә ныгытуга, ягъни гамәли эшкә, күнекмәләр бирүгә вакытның күпчелек өлеше сарыф ителә, кайбер утырышлар тулысы белән практик эшкә багышлана.

Түгәрәк лекция, практикум, иҗат ителгән әсәрләрне тәкъдим итү, проект эше яклау, очрашу-әңгәмә, экскурсия, кичә һәм башка формаларда да үткәрелә. Программа атнасына 2 дәрес исәбеннән төзелде. Түгәрәктә 10-11 нче сыйныф укучылары шөгыльләнә.

**Түгәрәкнең максаты:**

-сүзнең матурлыгын, туган телнең кеше тормышындагы алыштыргысыз ролен укучыларга төшендерү;

-туган як матурлыгын күрергә, аны сакларга өйрәтү;

-укучыларны әйләнә-тирәлеккә иҗади карарга өйрәтү, аларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

- укучыларда әдәби телгә мәхәббәт тәрбияләү, дөрес сөйләргә, фикерне дөрес итеп әйтергә, аңлатырга өйрәтү.

**Түгәрәкнең бурычлары:**

- балаларны иҗади дәртләндерү, аларның йөрәгендә иҗат чишмәсен уяту;
- көндәлек матбугат белән танышып баруга күнектерү;
- республикада, шәһәрдә, сыйныфта булган яңалыклар, истәлекле вакыйгаларны өйрәнеп, вакытлы матбугат жанрының берсендә хәбәрләр язарга өйрәтү;
- түгәрәк әгъзалары тарафыннан уңышлы дип табылган әсәрләрне республикада чыгып килә торган газета-журналга тәкъдим итү;

-төрле конкурсларда катнашу, укучыларның буш вакытларын файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

**Түгәрәгенең актуальлеге:**

Якташ язучыларның иҗатларын, әсәрләрен өйрәнү мәктәп программаларында урын алмаган. Шуны исәпкә алып, мәктәптә “Журналист әлифбасы” түгәрәге оештырылды.

<u>Ел ахырында түгәрәккә йөрүче укучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:</u>

- телдән һәм язмача бәйләнешле сөйләм төзергә;
- актуаль темага мәкалә язарга;
- якташ язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатларын белергә,
- шигъри рифмалар уйлап табарга;
- ел дәвамында әдәбият һәм сәнгать әһелләренә кагылышлы истәлекле даталар турында хәбәрдар булырга;
- сәламәтлеккә кагылышлы рубрикаларны кертү (рубрики про ЗОЖ);
- язылган материалны редакцияләргә;
- газетаны компьютерда җыя белергә.

**Тематик план**
*Атнасына 4 сәгать,*
*Барысы – 138 сәгать.*

**“Журналист әлифбасы” түгәрәге эшен планлаштыру**

| | **Эшнең эчтәлеге** | Сәг. сан | теоретик | практик | вакыты | үтәлеше |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Оештыру эшләре.** (Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү) | 2 | 1 | 1 | 5.09 | |
| 2 | **Компьютер ысуллары** | | | | | |
| | Клавиатура төзелеше, хәрефләр, символлар урнашуы белән таныштыру | 2 | 1 | 1 | 6.09 | |
| | Хәреф җыю режимнары(тел, баш хәреф). Татар хәрефләре | 2 | 1 | 1 | 12.09 | |
| | Шрифтлар, аларның төрләре белән танышу | 2 | 1 | 1 | 13.09 | |
| | Текст фрагментлары белән эшләү (күчерү, өстәп кую) | 2 | 1 | 1 | 19.09<br>20.09 | |
| | Газета-журналлардагы фоторәсемнәр. Рәсем ясау, рәсемгә исем куярга өйрәтү | 2 | 1 | 1 | 26.09 | |
| | Сканер ярдәмендә рәсемнәр кертергә өйрәнү | 2 | 1 | 1 | 27.09 | |
| | Документларга график объектлар өстәү | 2 | 1 | 1 | 3.10 | |
| | Җыелган текстның хаталарын тикшерү һәм төзәтү. Текстны бизәү алымнары. | 2 | 1 | 1 | 4.10 | |
| | Газетаның макетын төзү, рубрикаларны урнаштыру | 2 | 1 | 1 | 10.10 | |
| | Газетаның чираттагы санына материаллар җыю. Тупланган материалны компьютерда җыю | 4 | 2 | 2 | 11.10<br>17.10 | |
| | *Газетаны бастыру* | 2 | 1 | 1 | 18.10 | |
| 3. | **Журналистикада жанр төрләре** | | | | | |
| | *Хәбәри жанрлар:* | | | | | |
| | Хәбәр язарга өйрәнәбез. Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу. Сәламәт яшәү рәвеше рубрикасын тулыландыру. Рубрика про ЗОЖ | 4 | 2 | 2 | 24.10<br>25.10 | |
| | Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. | 4 | 2 | 2 | 7.11<br>8.11 | |
| | Интервью – иҗади гәпләшү | 4 | 2 | 2 | 14.11<br>15.11 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | *Аналитик жанрлар:* | | | | | |
| | Корреспонденция- җәмәгатьчелек иътибарын проблемага юнәлтә . Очерк язу күнегүләре. | 4 | 2 | 2 | 21.11<br>22.11 | |
| | Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт | 4 | 2 | 2 | 28.11<br>29.11 | |
| | Газетаның чираттагы санына материаллар җыю. Тупланган материалны компьютерда җыю | 4 | | 4 | 5.12<br>6.12 | |
| | *Газетаны бастыру* | 2 | | 2 | 12.12 | |
| 4. | **Газета- журналлар турында мәгълүматлар** | | | | | |
| | "Сабантуй", "Чистай хәбәрләре" газеталары, "Ялкын" журналына күзәтү ясау | 2 | 1 | 1 | 13.12 | |
| | Татарстанда һәм Россиядә чыга торган газета-журналлар турында мәгълүматлар бирү. Аларның төп рубрикалары. | 2 | 2 | | 19.12 | |
| | Мәкалә төрләре. Мәкалә - информация | 2 | 2 | | 20.12 | |
| | Мәкалә –бәяләмә. Мәкалә – рәхмәт. | 2 | 2 | | 26.12 | |
| | Мәкалә- сорау, мәкалә- үтенеч язу күнегүләре | 2 | | 2 | 27.12 | |
| | Мәкалә -.Начар гадәтләр, сәламәтлекккә зарар. Тәмәке, исерткеч эчемлекләр һәм наркотиклар турында кисәтү ясау.(Рубрика о вреде вредных привычек). | 2 | 1 | 1 | 9.01 | |
| 5. | **Шигырь, текст язарга өйрәнәбез** | | | | | |
| | Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре | 4 | 2 | 2 | 10.01<br>16.01 | |
| | Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү, текстлар уку. | 4 | 2 | 2 | 17.01<br>23.01 | |
| | Уеннар "Башын башлыйм, син тәмамла” | 2 | 1 | 1 | 24.01 | |
| | Газета-журналларда басылган шигырьләргә, текстларга күзәтү ясау. | 4 | | 4 | 30.01<br>31.01 | |
| | Төрле темаларга шигырьләр, текстлар иҗат итү. | 5 | 2 | 3 | 6.02<br>7.02<br>13.02<br>14.02<br>20.02 | |
| | Текстларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. | 5 | 3 | 2 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Газетаның чираттагы санына материаллар җыю. Тупланган материалны компьютерда җыю | 4 | | 4 | 21.02<br>27.02 | |
| | *<u>Газетаны бастыру</u>* | 2 | 1 | 1 | 28.02 | |
| 6. | **Татар халык авыз иҗаты** | | | | | |
| | Мәзәкләр, әкиятләр, кроссвордлар төзелеше б/н таныштыру, язарга тәкъдим итү | 4 | 2 | 2 | 6.03<br>7.03 | |
| | Мәкальләр, әйтемнәр Санамышлар. | 2 | 1 | 1 | 13.03 | |
| | Табышмаклар. Үзебез табышмак чыгарабыз. | 2 | 1 | 1 | 14.03 | |
| | Халык авыз иҗаты әсәрләреннән әкиятләр. Әкиятләрнең төзелеше. | 4 | 3 | 1 | 20.03<br>21.03 | |
| | Җырлар. Җырлы-бию уеннар. Җырлар иҗат итү. | 4 | 1 | 3 | 3.04<br>4.04 | |
| | Мәзәкләр. Без үзебез мәзәкче. | 4 | 2 | 2 | 10.04<br>11.04 | |
| | Г.Тукай туган көненә панорама - стенгазета чыгару. | 4 | 2 | 2 | 17.04<br>18.04 | |
| 7. | **Татар милли бәйрәмнәре** | | | | | |
| | Татар милли бәйрәмнәре. Карга боткасы | 2 | 1 | 1 | 24.04 | |
| | Татар милли бәйрәмнәре. Нәүрүз | 2 | 1 | 1 | 25.04 | |
| | Татар милли бәйрәмнәре. Сабан туе, җыен бәйрәмнәре. Кече Сабан туе | 2 | | 2 | 2.05 | |
| | Татар милли ризыклары. “Яраткан милли ризыгым” темасына мәкалә язу. | 4 | 2 | 2 | 8.05<br>15.05 | |
| 8. | **Батырлар янәшә яши** | | | | | |
| | Җиңү көне. **Алар онытылмас…** | 2 | 1 | 1 | 16.05 | |
| | Тынычлык телибез! **Сугыш һәм хезмәт ветераннарына багышлап шигырьләр язу,** | 2 | 1 | 1 | 22.05 | |
| | Газетаның чираттагы санына материаллар җыю. Тупланган материалны компьютерда җыю | 2 | 1 | 1 | 23.05 | |
| | *<u>Газетаны бастыру</u>* | 2 | 1 | 1 | 29.05 | |
| 9. | **Еллык эшләргә нәтиҗә ясау.** Иң яхшы яшь хәбәрчеләрне бүләкләү. | 2 | 1 | 1 | 30.05 | |
| | **Барлыгы** | **138** | | | | |

## “Журналист әлифбасы” программасы

**Оештыру эшләре. (1 сәг.)** Укучыларны түгәрәккә туплау, максат һәм бурычлар, планнар белән таныштыру, инструктажлар үткәрү.

**Компьютер ысуллары (13 сәг.)** Клавиатура төзелеше, хәрефләр, символлар урнашуы белән таныштыру. Презентацияләр, графика, диаграмма, билгеләмәләр, схемалар, рәсемнәр программасын өйрәтү.

**Журналистикада жанр төрләре (13 сәг.)** Хәбәри жанрлар: репортаж, интервью, хроника, очерк, памфлет, фельетон белән танышу. Хәбәр язарга өйрәнәбез. Гимназиядә булган вакыйга яки факт турында язу. Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу. Интервью – иҗади гаплэшү. Хисап (отчет) –сөйләшүгә корылган вакыйга турында сөйли.

Корреспонденция- җәмәгатьчелек иътибарын проблемага юнәлтә.

Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт**.**

**Газета- журналлар турында мәгълүматлар (6 сәг.)** Газета ничек ясала? Редколлегия составы, аларның вазифасы һәм эшчәнлеге. Хәбәрчегә хас сыйфатлар. Креативлык, культуралылык, хәбәрдарлык, зәвык һ.б. Минем яраткан газетам: яшьләрне кызыксындыручы рубрикалар, аларда күтәрелгән темалар, мәсьәләләр. “Атна” газетасына экскурсия. Элек чыккан саннары белән танышу. Газета алдаганны яратмый. Чынбарлыкны ачу, укучыга аны җиткерүдә журналист осталыгы. Газеталарга күзәтүләр. Газета-журналлардагы фоторәсемнәр. Рәсем ясау, рәсемгә исем куярга өйрәтү

**Шигырь, текст язарга өйрәнәбез. (15 сәг.)**Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре. Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен, хикәяләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү. Уеннар "Башын башлыйм, син тәмамла”. Газета-журналларда басылган шигырьләргә, тестларга күзәтү ясау. Төрле темаларга шигырьләр, текстлар иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау.

**Татар халык авыз иҗаты (12 сәг.)** Төрле темаларга (ел фасыллары, уеннар, сөю-сәгадәт...) шигырьләр язу.Мәзәкләр, әкиятләр, кроссвордлар төзелеше б/н таныштыру, язарга тәкъдим итү, стенгазета чыгару.

**Татар милли бәйрәмнәре (5 сәг.)** Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү. “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Сабантуй” бәйрәмнәре турында текстлар, фотолар, шигырьләр табу.

**Батырлар янәшә яши (4 сәг.)** Бөек Ватан сугышында катнашучы безнең шәһәребезнең - солдатлар язмышы, тыл ветераннары, сугыш чоры балалары турында белемнәрне тулыландыру, мәкаләләр язу.

**Еллык эшләргә нәтиҗә ясау. (1 сәг.)** Уку елы ахырында иҗат түгәрәгенең ачык утырышын уздыру. Газеталар буенча фикер алышу. Түгәрәккә йомгак. Нәтиҗәләр чыгару. Аеруча актив хәбәрчеләрне билгеләү, аларны бүләкләү.

**Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән уңышлар.**

Программа түгәрәк җитәкчесеннән фәнни-педагогик әзерлеккә ия булуны таләп итә. Укытучының филология, тарих, журналистика, рәсем сәнгате буенча билгеле бер күләмдә белеме, сәләте, күнекмәләре булырга тиеш. Һәрдаим эзләнгәндә, бай материал туплап, белгечләр белән киңәшләшеп, аларны эшчәнлеккә җәлеп иткәндә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Чистай шәһәре шартларында моның үз мөмкинлекләре бар.

Белем бирү программасы шактый катлаулы, шуңа күрә түгәрәккә йөрүче балаларның дәресләргә даими йөрүе кирәк. Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: теоретик материал һәр дәрестә гамәли эш белән ныгытылырга тиеш. Укучылар үз көчләре белән нәрсәдер иҗат итсәләр, язсалар, кызыксыну арта. Шуны истә тотып, программада гамәли дәресләр өстенлек итә.

Күрсәтмә материалны мультимедиа чаралары аша файдалану уңышлы. Ул дәресне җанлырак итә, педагогның эшен бермә-бер җиңеләйтә. Әлеге программаны тулысынча тормышка ашыру өчен берләшмә утырышлары үткәрелә торган кабинетка интернет челтәренә тоташкан компьютер, ноутбук, фотоаппарат, принтер кирәк.

Курс буенча методик эшкәртмәләрнең аз булуы эштә күп кыенлыклар тудыра. Программа авторы бу юнәлештә туктаусыз эзләнү алып бара. Программа материалын уңышлы үзләштергән укучы түбәндәге белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- мәктәптә яки группада үткәрелгән чара турында хәбәр яза;
- ритм һәм рифманы иҗат эшендә дөрес итеп куллана;
- журналистикадагы жанр төрләрен һәм үзенчәлекләрен дөрес һәм урынлы файдалана ала;
- һәр эшендә пөхтәлеккә, язмаларының дөреслегенә ирешергә омтыла;
- журналистика барлыкка килү, үсеш тарихыннан хәбәрдар, хәзерге шартларда журналистикадагы үсеш тенденцияләре белән кызыксына, яңалыкларны вакытында белеп бара;
- сүзләрдән образ тудыра, художестволы чаралар ярдәмендә иҗат итә белә;
- үзе иҗат иткән шигырьне сәнгатьле итеп сөйли;

- үз милләтенең культурасы, сәнгате һәм әдәбияты белән горурлану хисләре кичерә;
- хәзерге татар әдәби телендә аралаша һәм сәхнәдән торып сөйли белә;
- иҗади бәйгеләрдә катнаша.

**Әдәбият исемлеге:**


1. Гарифуллин В.Г. "Үткен каләм, үткер күз”. Казан: Тат. китап нәшр.,1995 – 165 б.
2. Гарифуллин В.Г. "Журналистның иҗади эшчәнлеге нигезләре” Казан, 2004 – 205 б.
3. Хәйруллина А.Х. Тел күрке – сүз (матур сөйләргә өйрән). / А.Х.Хәйруллина. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1978. – 113 б.
4. “Чистай хәбәрләре”, "Атна”, “Өмет” газеталары, "Сабантуй”, "Сабыйга” журналлары.
5. 5-11 нче сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. Казан ”Мәгариф” нәшрияты, 2000ел
6. И.М.Низамов//Ничек әйтергә? Ничек язарга?// Казан ”Мәгариф” нәшрияты,1990ел
7. Мәкалә яза беләсеңме?/ Мәгариф,№ 12, 1998ел, 23б.